СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**30.05.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 404**

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 96 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы Контроль-хисап палатасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

« Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 сентябрендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 96 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 23 статьяның 1 пункты түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

Контроль-хисап палатасы вазифаи затларының еллык төп түләүле отпуск озынлыгы 30 календарь көн.

Контроль-хисап палатасыны вазыйфаи затларының тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпускның дәвамлылыгы муниципаль вазыйфаны, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән һәр ел өчен, шулай ук дәүләт вазыйфасын һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән өчен бер календарь көн исәбеннән исәпләнә. Контроль-хисап палатасы вазыйфаи затларының тиешле еллар эшләгән өчен еллык төп түләүле отпускның һәм еллык өстәмә түләүле отпускның гомуми озынлыгы 45 календарь көннән арта алмый.

2. Әлеге карарны «Интернет». мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Совет рәисе** **М. П. Афанасьев**